| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_28 ноябрь 2013 № _271 №лы

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазифалары билгеләнгәндә гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, шулай ук вазифаларга керелгәндә гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырасы тиешле вазифалар тезмәсенең раслануы турында.**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 27 июль 2004 79-ФЗ №лы Федераль законы, «Коррупцияга каршы гамәлләр турында» 25 декабрь 2008 273-ФЗ №лы Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупцияга каршы гамәлләр турында» Федераль законының аерым нигезләмәләренең тормышка ашыру буенча чаралар турында» 21 июль 2010 925-ФЗ №лы боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазифалары билгеләнгәндә һәм вазифаларга керелгәндә гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырасы тиешле вазифалар тезмәсенең раслануы турында» 30 декабрь 2009 УП-701 №лы боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының «Вазифалар алыштырылганда гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган

балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырасы тиешле вазифалар тезмәсенең раслануы турында» 22 апрель 2013 УП-329 №лы боерыгы буенча
б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазифалары билгеләнгәндә гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, шулай ук вазифалар алыштырылганда гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырасы тиешле вазифалар тезмәсен расларга.

2. Билгеләргә:

Әгәр дәүләт идарәсенең аерым функцияләре Дәүләт комитетында дәүләт эшчеләренең уз-узен тоту таләпләрен үтәү һәм ул оешманың мәнфәгатьләре конфликтын чишү буенча комиссиянең (алга таба - Комиссия) ризалыгы белән дәүләт эшчесенең вазифа (хезмәт) йөкләмәләренә кергән булса, тезмәдә кергән дәүләт хезмәте вазифасына кергән граждан дәүләт хезмәтеннән алынганнан соң ике ел эчендә эш килешүе нигезендә оешмада вазифаларга керергә һәм (яки) бер ай эчендә граждан-хокукый килешү (граждан-хокукый килешүләр) шартларында кимендә йөз сум бәясенә шул оешмада эшләр башкарырга хокукы бар;

комиссия гражданның эш килешүе нигезендә оешмада вазифаларга керергә һәм (яки) граждан-хокукый килешү шартларында шушы оешмада эш башкаруга ризалыгын белдерүе турында язма мөрәҗәгате килгәннән соң җиде көн эчендә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш, һәм алынган карар турында гражданга бер эш көне эчендә язма хәбәр җибәрергә һәм өч эш көне эчендә телдән хәбәр итергә тиеш;

дәүләт эшеннән алынганнан соң ике ел эчендә югарыда күрсәтелгән Тезмә буенча дәүләт хезмәтендә вазифага кергән булган граждан эш килешү яки ошбу боерыкның 2 нче пунктында икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкаруга раждан-хокукый килешү төзегәндә үзенең соңгы хезмәте турында эш бирүчегә белдрергә тиеш;

дәүләт эшеннән алынганнан соң югарыда күрсәтелгән Тезмә буенча дәүләт хезмәтендә вазифага кергән булган гражданның ошбу боерыкның 2 нче пунктында дүртенче абзацында күрсәтелгән таләпне үтәмәү әлеге гражданны күрсәтеп ясалган ошбу боерыкның 2 нче пунктының абзацында күрсәтелгән эшләрнең (хезмәтләрнең) башкаруына эш яки граждан-хокукый килешүнең бетүенә алып бара;

эш бирүче ике ел эчендә югарыда күрсәтелгән Тезмә буенча дәүләт эшеннән алынганнан соң дәүләт хезмәтендә вазифага кергән булган граждан белән ошбу боерыкның 2 нче пунктында абзацта күрсәтелгән эш яки граждан-хокукый килешү ясаганда эш бирүче ун көн эчендә дәүләт эшчесенең соңгы тапкыр хезмәт иткән эш урының эшкә алучысы ның (эш бирүчесенең) вакиленә мондый килешү ясаганы турында хәбәр итергә тиеш;

эш бирүченең ошбу боерыкның 2 нче пункты алтынчы абзацында билгеләнгән йөкләмәне үтәмәү хокук бозу итеп санала һәм Россия Федерациясе законнары буенча җаваплылыкка алып бара;

гражданның ошбу боерыкның 2 нче пунктының абзацында күрсәтелгән боерыкны үтәвен, федераль законнарда күрсәтелгән очракларда эш килешүе нигезендә оешмадагы вазифага керү һәм (яки) граждан-хокукый килешү шартларында шушы оешмада, әгәр ул оешманың дәүләт идарәсенең аерым функцияләре граждан яки муниципаль эшченең вазифа йөкләмәләренә кермәгән булса, эш башкаруны тыюының үтәвен, һәм эш бирүченең эш килешү шартларын үтәвен яки әлеге граждан белән ясалган граждан-хокукый килешү шартларын үтәвенең тикшерелүе Россия Федерациясе норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә башкаралырга тиеш;

3. Кадрлар бүлеге:

3.1. Дәүләт комитетының бөтен дәүләт граждан эшчеләрен ошбу боерык белән таныштырырга;

Югарыда күрсәтелгән Тезмәне раслану көненнән башлап өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты янында дәүләт эшчеләре эшләре Департаментына һәм Татарстан Республикасы антикоррупцион сәясәтенең башкаралу бүлегенә тапшырырга һәм үзгәртүләр кертелгән очракта үзгәртүләр кертелгән көненнән башлап бер атна эчендә тапшырырга.

4. Информатизация бүлегенә ошбу боерыкны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацион челтәренә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Дәүләт комитетының сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазифалары билгеләнгәндә һәм вазифаларга керелгәндә гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырасы тиешле вазифалар тезмәсенең раслануы турында» 06.05.2013 124к №лы боерыгы.

6. Әлеге боерык рәсми рәвештә нәшер ителгән көнне гамәлгә керә.

7. Ошбу боерыкның башкаралуының контролен Кадрлар бүлеге башлыгы Т.А.Толстаяга тапшырырга

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
28 ноябрь 2013  371 №лы
карарының Кушымтасы

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәте вазифаларының тезмәсе, гражданнар үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының)  һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, шулай ук вазифаларга керелгәндә гражданнарның үз керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында, иренең (хатынының)  һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милеккә кагылышлы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырырга бурычлы

1. Татарстан Республикасы «башлыклар» категориясендәге Дәүләт граждан хезмәте вазифалары:

1.1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе беренче урынбасары;

1.2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары;

1.3. эшләр җитәкчесе;

1.4. идарә башлыгы;

1.5. бүлек җитәкчесе;

1.6. бүлек җитәкчесе урынбасары;

2. Татарстан Республикасы «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге Дәүләт граждан хезмәте вазифалары:

рәис ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы «белгечләр» категориясендәге Дәүләт граждан хезмәте вазифалары:

3.1. административ практика бүлеге; өлкән киңәшче, алдынгы консультант;

3.2. гражданнар белән эшләү бүлеге: алдынгы консультант;

3.3. технологик тоташтыру өчен түләү билгеләү бүлеге: өлкән киңәшче, алдынгы консультант;